**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6624**
**12.11.2018**

Шәһәр хакимияте башлыгының «Яр Чаллы шәһәрендә милеккә җир участоклары яки андый җир участокларына аренда килешүләре төзү хокукын сату буенча сатулар үткәрү тәртибе турында» 2004 елның 1 июнендәге 1068 нче карары үз көчен югалткан дип тану турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе һәм РСФСРның аерым норматив хокукый актлары һәм норматив хокукый актларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану һәм СССРның аерым норматив хокукый актларының Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булмавын тану турында» 2014 елның 22 октябрендәге 1090 нчы карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.25 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Шәһәр хакимияте башлыгының «Яр Чаллы шәһәрендә милеккә җир участоклары яки андый җир участокларына аренда килешүләре төзү хокукын сату буенча сатулар үткәрү тәртибе турында» 2004 елның 1 июнендәге 1068 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин